**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ № _________

**«Шифа» муниципаль унитар предприятиесен ликвидацияләү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61, 62, 63 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Актаныш авылы, Тукай урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан, «Шифа» муниципаль унитар предприятиесен 2021 елның 24 июненнән ликвидацияләргә.

2. «Шифа» муниципаль унитар предприятиесен ликвидацияләү чараларын үткәрү буенча Мосабиров Шамил Алмаз улын, ликвидатор итеп билгеләргә.

3. Ликвидатор Мосабиров Шамил Алмаз улына:

- ликвидацияләү барышында ачыкланган, кредит бурычларын түләү буенча чаралар күрергә;
- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына раслауга, арадаш ликвидация һәм ликвидация балансларын тапшырырга;
- 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдәге законнарда каралган «Шифа» муниципаль унитар предприятиесен ликвидацияләү буенча чараларны тормышка ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына «Шифа» муниципаль унитар предприятиесенә элек хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне алга таба файдалану турында тәкъдимнәр бирергә.

5. Әлеге карарны «Актаныш таннары» газетасының рәсми басмасында бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatar.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев